ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 18 апреле** **Чистай шәһәре** **№ 285**

Чистай муниципаль районы буенча
2022 елның II кварталына торакның
1 квадрат метр гомуми мәйданының
нормативы турында

«2020-2025 елларга Чистай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын тормышка ашыру максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының «2022 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында»2022 елның 29 мартындагы 215/пр номерлы боерыгы нигезендә, «ТР Бәяләүчеләр союзы» КПның «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2022 елның 7 февралендәге 37 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елның II кварталына Чистай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының бәясе нормативын (сумнарда) 61 796 (алтмыш бер мең җиде йөз туксан алты) сум күләмендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р.Хәсәнов